

Иярчен
вакыт
җөмлә.

# ТЕСТ

## 1.ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘ -

1) ияреп килгән һәм баш җөмләдән чыгып куелган сорауга җавап булып килгән җөмлә

2) иярченле кушма җөмләнең беренче җөмләсе

## 2.БАШ ҖӨМЛӘ -

1) теркәгечле тезмә кушма җөмләнең беренче җөмләсе

2) ияртеп килә торган һәм аннан чыгып, башка җөмләгә сорау куела торган җөмлә

**3. ТӨЗЕЛЕШЕ БУЕНЧА ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘНЕҢ ТӨРЛӘРЕ**

1) теркәгечле тезмә кушма

2) аналитик һәм синтетик

**4.АНАЛИТИК ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘ -**

1) хәбәре булмаган иярчен җөмлә

2) баш җөмләгә үзенең хәбәре составында тормый торган чаралар ярдәмендә ияргән җөмлә

**5.СИНТЕТИК ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘ -**

1) баш җөмләгә үзенең хәбәре составындагы чаралар ярдәмендә ияргән җөмлә

2) баш җөмләгә көттерү интонациясе ярдәмендә ияргән җөмлә

**6. АНАЛИТИК ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘЛӘРНЕ БАШ ҖӨМЛӘГӘ БӘЙЛӘҮЧЕ ЧАРАЛАР**

1) мөнәсәбәтле сүзләр, ияртүче теркәгеч һәм теркәгеч сүзләр, көттерү интонациясе

2) җыючы теркәгечләр, кушымчалар, санау интонациясе

**7.ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘЛӘР МӘГЪНӘ ЯГЫННАН ТӨРЛӘРГӘ**

1) нинди җөмлә кисәге мәгънәсендә килүенә карап бүленә

2) нинди кушымчалар ялгануга карап бүленә

**8.ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘЛӘРНЕҢ МӘГЪНӘ ЯГЫННАН ТӨРЛӘРЕ**

1) 10

2) 14

# Тестны тикшер!

Бәяләү: хатасыз- “5”ле

1-2 хата- “4”ле

3 хата- “3”ле

4 хата- “2”ле

**1.ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘ -**

**1) ияреп килгән һәм баш җөмләдән чыгып куелган сорауга җавап булып килгән җөмлә**

2) иярченле кушма җөмләнең беренче җөмләсе

**2.БАШ ҖӨМЛӘ -**

1) теркәгечле тезмә кушма җөмләнең беренче җөмләсе

**2) ияртеп килә торган һәм аннан чыгып, башка җөмләгә сорау куела торган җөмлә**

**3. ТӨЗЕЛЕШЕ БУЕНЧА ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘНЕҢ ТӨРЛӘРЕ**

1) теркәгечле тезмә кушма

**2) аналитик һәм синтетик**

**4.АНАЛИТИК ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘ -**

1) хәбәре булмаган иярчен җөмлә

**2) баш җөмләгә үзенең хәбәре составында тормый торган чаралар ярдәмендә ияргән җөмлә**

**5.СИНТЕТИК ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘ -**

**1) баш җөмләгә үзенең хәбәре составындагы чаралар ярдәмендә ияргән җөмлә**

2) баш җөмләгә күтәрү интонациясе ярдәмендә ияргән җөмлә

**6. АНАЛИТИК ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘЛӘРНЕ БАШ ҖӨМЛӘГӘ БӘЙЛӘҮЧЕ ЧАРАЛАР**

**1) мөнәсәбәтле сүзләр, ияртүче теркәгеч һәм теркәгеч сүзләр, күтәрү интонациясе**

2) җыючы теркәгечләр, кушымчалар, санау интонациясе

**7.ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘЛӘР МӘГЪНӘ ЯГЫННАН ТӨРЛӘРГӘ**

**1) нинди җөмлә кисәге мәгънәсендә килүенә карап бүленә**

2) нинди кушымчалар ялгануга карап бүленә

**8.ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘЛӘРНЕҢ МӘГЪНӘ ЯГЫННАН ТӨРЛӘРЕ**

1) 10

**2) 14**

# Иярчен җөмләләр

- Иярчен ия җөмлә
- Иярчен хәбәр җөмлә
- Иярчен тәмамлык җөмлә
- Иярчен аергыч җөмлә
- ?
- ?
- ?

# Иярчен җөмләләр

- Иярчен ия җөмлә
- Иярчен хәбәр җөмлә
- Иярчен тәмамлык җөмлә
- Иярчен аергыч җөмлә
- Иярчен хәл җөмлә
- ?
- ?

# Иярчен хәл җөмләләр

Иярчен вакыт җөмлә

?

?

?

?

?

?

?

# Иярчен вакыт җөмлә

1.Кояш кайчан нарат биеклеге булып күтәрелә , шул чакта Кама өсте чуп-чуар була.(М.Ә)
2.Сәйдәшев бер хәрәкәт белән оркестрны уйнаудан туктатты, шул арада музыкантлар тагын ниндидер сагышлы көй уйный башладылар.(Ф.С.-н)
3.Әнием эштән кайтуга, мин кайнар ашны өстәлгә китереп куйдым.
4.Берникадәр вакыт узганнан соң, кызның тагын моңлы җыры ишетелде.
5.Әти кайтканчы , син бездә торып тор.
6.Кояш батар алдыннан,каты җил чыкты.

**1 нче бирем.** Һәр җөмләдә баш кисәкләрне, иярчен һәм баш җөмләләрне, бәйләүче чараларны әйтергә. Схемаларын төзергә.

**2 нче бирем.** Югарыда тикшерелгән иярчен вакыт җөмләләрнең төзелеш ягыннан төрләрен әйтергә һәм дәлилләргә.

**3 нче бирем.** Тыныш билгеләренең куелышын дәлилләргә.

# Иярчен вакыт җөмлә

- баш җөмләнең вакыт хәле урынында килә;

-баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән вакыт хәлен ачыклый;

- кайчан? кайчаннан бирле? кайчанга чаклы?

баш җөмләгә бәйләнә

1)парлы һәм ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр;

аналитик

1)фигыль һәм килеш кушымчалары

2)бәйлек һәм бәйлек сүзләр

синтетик

# 1 нче бирем. Схемаларга туры килгән җөмләләрне табарга.

**Схемалар.**

1.( ...  ),[ шул вакыт...].

2.(... -ү белән ), [... ] .

3.(... -ганчы ), [...  ]  .

4.(...-ган чакта ), [... ].

**Җөмләләр.**

1.Ул елмайган чакта, якты кояш көлеп торсын синең йөзеңдә.

2.Ишек ачылды , шул вакыт карт укымышлының иелгән гәүдәсе, чал чәчле башы күземә ташланды.

3.Хәсән әфәндегә безгә килергә рөхсәт бирелү белән, без йөрешә башладык.

4.Көзге эшләр башланганчы , алты почмаклы өй салынып бетте.

# Өй эше.

1.Әдәбият дәреслегеннән  иярчен вакыт җөмләсе булган 4 кушма җөмлә язып алырга .